**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
|---|---|
| 13.06.2023 | № 749 |

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының беренче сыйныфына алты яшь тә алты айдан кечерәк һәм сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны кабул итү тәртибен раслау турында» 2022 елның 20 июнендәге 604 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 67 статьясының 1 пункты, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында» 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы һәм кадрлар үзгәрешләре нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренең 1 сыйныфына агымдагы елның 1 сентябренә алты яшь тә алты айдан кечерәк һәм сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны кабул итү турында ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) Гаризаларны карау буенча муниципаль комиссия составыннан түбәндәгеләрне чыгарырга: Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарын - Шәйдуллин Дамир Фәрит улын, “Биектау район үзәк хастаханәсе” ДАССУ район педиатрын - Гостюнина Евгения Константиновнаны.

2. Биектау муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренең 1 сыйныфына агымдагы елның 1 сентябренә алты яшь тә алты айдан кечерәк һәм сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны кабул итү турында ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) Гаризаларны карау буенча муниципаль комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә: Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен - Шәйдуллин Дамир Фәрит улын, “Биектау район үзәк хастаханәсе” ДАССУ район педиатрын - Ганеева Гөлназ Илгиз кызын.

3. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырып игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин